**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 11 гыйнвары 44 номер

**КАРАР**

**«Лаеш шәһәрендә «Балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт учреждениесе исемен үзгәртү һәм уставны яңа редакциядә раслау турында» 2008 елның 21 гыйнварындагы 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында " 2023 елның 19 декабрендәге 618-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, КАРАР ИТӘМ:

1. «Лаеш шәһәрендә «Балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт учреждениесе исемен үзгәртү һәм уставны яңа редакциядә раслау турында» 2008 елның 21 гыйнварындагы 27 номерлы карарына, яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

1) **3.16 пунктта** «укучыларга карата» сүзләреннән соң түбәндәге сүзләрне өстәргә:

- "педагогик хезмәткәрләргә һәм мондый оешманың башка хезмәткәрләренә";

2) **4.5 пунктны** түбәндәге эчтәлектәге пункт белән тулыландырырга:

- башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку программаларын үзләштергәндә, уку дәресләрен үткәргәндә хәрәкәтчән радиотелефон элемтәсе чараларын кулланмаска, моңа укучыларның, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың хезмәткәрләренең гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч янау очраклары барлыкка килү, башка ашыгыч очраклар керми.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Г.Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**